| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 07 апрель 2023 ел | № 2-68 |

ТР Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, 2021елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар, 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 1ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатыннан, Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 февралендәге 1-61 номерлы крары белән расланган (12.02.2020 № 1-77, 20.10.2020 № 1-4, 23.11.2020 № 1-6, 22.12.2020 № 1-8, 22.06.2021 № 4-24, 15.07.2021 № 1-25, 06.02.2023 № 2-65 карарлары редакциясендә) ТР Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгәтүбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 19.7 нче пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«19.7. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан тәкъдим ителә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тәкъдим ителә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә муниципаль хезмәткә кергәндә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар, муниципаль хезмәткәрләрнең "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән бурычларны үтәүләре Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла.»;

1.2. 19.8 нче пунктны  үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«19.8. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын контрольдә тотучы Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе яки күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи зат) Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Норлат
авыл җирлеге  башлыгы                                                       М.Х. Закиров